# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

Мөлкәтнең сакланышын тәэмин итмәгән өчен
административ җаваплылык турында

Әлеге Закон, милек рәвешләренә карамастан, предприятиеләр, учреждениеләр, оешмалар мөлкәтенең сакланышын тәэмин итү өлкәсендә милекне яклауга һәм хокук бозуларны кисәтүгә юнәлдерелгән.

1 статья. Татарстан Республикасында объектларның техник ныгытылу һәм сигнализация белән җиһазлану кагыйдәләрен бозуларны бетерү турында эчке эшләр органнарының күрсәтмәләрен үтәмәгән өчен –

предприятиеләрнең, учреждениеләрнең һәм оешмаларның җитәкчеләренә хезмәт өчен түләүнең 5 минималь күләменә кадәр штраф салына.

Мөлкәтне урлау шарты булырлык шундый ук гамәлләр өчен –

предприятиеләрнең, учреждениеләрнең һәм оешмаларның җитәкчеләренә хезмәт өчен түләүнең 10 минималь күләменә кадәр штраф салына.

Искәрмә. 1 статьяның беренче өлешендә күрсәтелгән объектлар дигәндә наркотик матдәләр, корал, сугыш кирәк-яраклары тупланган биналар, корылмалар һәм законнар белән махсус саклау режимы билгеләнгән башка объектлар күз алдында тотыла.

2 статья. Әлеге Законда каралган административ хокук бозулар турындагы беркетмәләр эчке эшләр органнарының шуңа вәкаләтле урындагы затлары тарафыннан төзелә һәм биш көн эчендә судка җибәрелә.

3 статья. Әлеге Законда каралган административ хокук бозулар турындагы эшләр административ хокук бозулар турындагы законнарда билгеләнгән тәртиптә һәм вакытта район (шәһәр) суды (судьясы) тарафыннан каралалар.

4 статья. Әлеге Законда каралган хокук бозулар өчен штрафлар түбәндәгеләргә җибәрелә дип билгеләргә: 75 проценты - административ материалларны карау урыны буенча шәһәр, район бюджетларына, 25 проценты - Татарстан Республикасы Эчке эшләр министрлыгының Ведомстводан тыш саклау идарәсенең махсус счетына.

5 статья. Әлеге Законны басылып чыккан көненнән гамәлгә кертергә.

6 статья. "Дәүләт милкендәге һәм коммуналь милектәге мөлкәтнең, акчаларның һәм кыйммәтле кәгазьләрнең сакланышы өлкәсендәге хокук бозулар өчен административ җаваплылык турында" Татарстан Республикасы Законы (Татарстан Югары Советы Җыелма басмасы, 1993, N 5); "Дәүләт милкендәге һәм коммуналь милектәге мөлкәтнең, акчаларның һәм кыйммәтле кәгазьләрнең сакланышы өлкәсендәге хокук бозулар өчен административ җаваплылык турында" Татарстан Республикасы Законын гамәлгә кертү тәртибе хакында" Татарстан Республикасы Югары Советы карары (Татарстан Югары Советы Җыелма басмасы, 1993, N 5) үз көчен югалткан дип танырга.

Татарстан Республикасы
Президенты — М.Шәймиев

Казан шәһәре,
1998 елның 25 декабре
N I94I